ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

1. Социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның салым ставкасын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

5 процент – социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым исәбе мәгълүматлары буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап биш салым чоры дәвамында;

10 процент – социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым исәбе мәгълүматлары буенча беренче табыш алынган салым чорыннан санала торган алтынчы салым чорыннан башлап унынчы салым чоры тәмамланганчы.

2. Әгәр резидент социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән ул резидентлар реестрына кертелгән салым чорыннан башлап өч салым чоры дәвамында табыш алмаган булса, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган сроклар мондый салым түләүче өчен ул резидентлар реестрына кертелгән салым чорыннан санала торган дүртенче салым чорыннан исәпләнә башлый.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган (эшчәнлеккә бәйле тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) һәм башка эшчәнлек башкарганда алынган (тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) исәбе резидентлар тарафыннан һәркайсы аерым алып барылганда гына кулланыла.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 13 феврале
№ 5-ТРЗ